# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 1 Закона Республики Татарстан «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для резидентов территорий опережающего социально-экономического развития, созданных на территориях монопрофильных муниципальных образований (моногородов) Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 ноября 2020 года

## Статья 1

Внести в статью 1 Закона Республики Татарстан от 13 февраля 2016 года № 5-ЗРТ «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для резидентов территорий опережающего социально-экономического развития, созданных на территориях монопрофильных муниципальных образований (моногородов) Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 1 – 2; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 38 (часть I) следующие изменения:

1) в абзаце первом части 1 слова «в отношении прибыли, полученной от деятельности, осуществляемой при исполнении соглашений об осуществлении деятельности на территории опережающего социально-экономического развития,» исключить;

2) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Налоговые ставки, установленные частью 1 настоящей статьи, применяются налогоплательщиками-резидентами в порядке и на условиях, предусмотренных статьей $284^4$ Налогового кодекса Российской Федерации.»;

3) часть 3 признать утратившей силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении одного месяца со дня его официального опубликования, но не ранее 1-го числа очередного налогового периода по налогу на прибыль организаций.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 ноября 2020 года
№ 81-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең беренче абзацында «Социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнгән территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары салым түләүче резидентлар тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының $284^{4}$ статьясында каралган тәртиптә һәм шартларда кулланыла.»;

3) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, ләкин оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 27 ноябрь
№ 81-ТРЗ